РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024 ел г. Альметьевск №2196

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районының (Әлмәт шәһәре) район үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2022 елның 9 декабрендәге 2933 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм күрсәтелгән субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүгә гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районының (Әлмәт шәһәре) район үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар

заказ № 1-851

кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2022 елның 9 декабрендәге 2933 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 9 июнендәге 1810 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
Карарга 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль
районының (Әлмәт шәһәре) район
үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан
Әлмәт муниципаль районының авыл
торак пунктларына беренче кирәк-ярак
товарларын китерү белән бәйле
кулланучылар кооперациясе
оешмаларының чыгымнары өлешен
каплауга Әлмәт муниципаль районы
бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районының (Әлмәт шәһәре) район үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия алу хокукын дәгъвалаучы юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы
КОМИССИЯ СОСТАВЫ

1. Комиссия рәисе, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Рәис урынбасары, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм сәнәгать Идарәсе башлыгы;
Комиссия әгъзалары:
3. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә, куллану хезмәтләре һәм эшкуарлыкны үстерү бүлеге башлыгы;
4. Авыл җирлекләренең социаль инфраструктурасын үстерү секторы мөдире;
5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча).».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Р06-12061/12 ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ ИНН 1644035822 КПП 164401001 ОГРН 1051605067172